ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» ноябрь 2020 ел № 384

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар азык белән тәэмин итүгә һәм 2021 елда туклану белән тәэмин итүгә көндәлек акчалата түләү күләмен билгеләү турында норматив чыгымнарны раслау хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2020 елның 06 октябрендәге 908 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 851 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында бер укучыга исәпләнгән башлангыч гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча белем алучыларны оештыруга һәм түләүсез кайнар туклану белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны көнгә бер укучыга түбәндәгечә расларга:

- 53,41 сум күләмендә;

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында бер укучыга белем бирү чорында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча белем алучыларны туклану белән тәэмин итүгә көндәлек акчалата түләү күләмен 2021 елга түбәндәгечә билгеләргә:

- 8,0 сум күләмендә;

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны үтәү кысаларында чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының

рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э.Акбашев**